# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Зур Сукаеш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**14 ноябрь 2025 ел** **№ 1**

2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 45,69 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Уставы нигезендә 2025 елның 14 ноябрендә, түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары (җыен) нәтиҗәләре буенча гаражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

«Сез 2026 елда Сукаеш авыл җирлеге Зур Сукаеш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 Төркем инвалидларыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан , гаилә әгъзасы мобилизацияләнгән, хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән һәм махсус хәрби операциягә җибәрелгән гаиләләрдан тыш 400 сум күләмендә һәм 2 Төркем инвалидларыннан, 80 яшьтэн өлкәннәрдэн 200 сум сум күләмендә үзара салым кертү  һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Зур Сукаеш авыл җирлегендә урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм алмаштыру, урам яктыртуын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Молодежная урамына, Садовая урамына, Советская урамына, Школьная урамына салу өчен вак таш сатып алу, төяү, ташу);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (трактор йөртүченең юлларны кардан чистарту хезмәте өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 287 гражданнар жыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 161.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен 161,

«КАРШЫ» позициясе өчен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Зур Сукаеш торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип танырга.
2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

«Сез 2026 елда Сукаеш авыл җирлеге Зур Сукаеш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 Төркем инвалидларыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан , гаилә әгъзасы мобилизацияләнгән, хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән һәм махсус хәрби операциягә җибәрелгән гаиләләрдан тыш 400 сум күләмендә һәм 2 Төркем инвалидларыннан, 80 яшьтэн өлкәннәрдэн 200 сум күләмендә үзара салым кертү  һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Зур Сукаеш авыл җирлегендә урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм

электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм алмаштыру, урам яктыртуын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Молодежная урамына, Садовая урамына, Советская урамына, Школьная урамына салу өчен вак таш сатып алу, төяү, ташу);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (трактор йөртүченең юлларны кардан чистарту хезмәте өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу).»

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Сукаеш авыл җирлеге мәгълүмати стендларында тбәндәге адрес буенча: Зур Сукаеш авылы, Совет ур., 30 йорт, һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сукаеш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Сукаеш авыл җирлеге башлыгы: Закирова З.Җ.